РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 8 декабре № 51

Түбән Кама шәһәр Советының 2006 елның 13 октябрендәге 24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә иҗтимагый фикер алышулар һәм гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре Уставы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2006 елның 13 октябрендәге 24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә иҗтимагый фикер алышулар һәм гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4.4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4. Гавами тыңлауларны, үткәрү вакытын һәм урынын күрсәтеп, билгеләү турында мәгълүмат, шулай ук гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 7 календарь көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә), шул исәптән Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга, шулай ук «Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә (Бердәм порталдан файдаланганда) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы» (алга таба – Бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш.

Түбән Кама шәһәрендә яшәүчеләргә хәбәр итү максатларында, гавами тыңлаулар билгеләү турында мәгълүматны һәм муниципаль норматив хокукый акт проектын Бердәм порталда урнаштыру, гавами тыңлаулар үткәрүнең инициаторы булган, җирле үзидарә органының шәхси кабинетын файдаланып, Бердәм порталның кире элемтә платформасының тиешле бүлегендә (алга таба - органның шәхси кабинеты) әлеге пунктның беренче абзацы билгеләнгән срокта Башкарма комитетның тиешле структур бүлекчәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.»

4.5 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча фикер алышуга чыгарылган искәрмәләр һәм тәкъдимнәр Түбән Кама шәһәре халкы тарафыннан «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә, анда авторизацияләнгәннән соң,

Бердәм порталны файдаланып кертелә. Шул ук вакытта искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертү гавами тыңлаулар билгеләү турында мәгълүматны һәм гавами тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проектын бастырып чыгару датасыннан башлана һәм гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана. Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр керткәндә, Түбән Кама шәһәре халкы шулай ук үзенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), гражданның шәхесен раслаучы төп документның реквизитлары, туу датасы һәм яшәү урыны буенча теркәлү адресы турында мәгълүмат җибәрә. Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр органның шәхси кабинетына җибәрелә. Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр органның шәхси кабинетына җибәрелә»;

7.4 пунктының беренче абзацын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

«Кабул ителгән карарларны дәлилләп нигезләүне дә кертеп, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре бастырып чыгарыла (халыкка җиткерелә), шул исәптән Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында һәм Бердәм порталда гавами тыңлаулар уздырылганнан көннән соң 5 календарь көннән дә соңга калмыйча (Бердәм порталдан файдаланганда) урнаштырыла.»

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Түбән Кама шәһәре Мэры
вазыйфаларын башкаручы,
Мэр урынбасары

М.В. Камелина